МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ДОМ ДЕТСТВА И ЮНОШЕСТВА»
МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Принята на заседании
педагогического совета
Протокол № 1
от «31» августа 2023 года

Утверждаю
Директор МБОУДО
«Дом детства и юношества»
_________ /Ефимов А.М./
Приказ № 119
от «31» августа 2023 года

# ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА
## «Литературное краеведение»

**Направленность: туристско-краеведческое**

**Возраст обучающихся: 11-17 лет**

**Срок реализации: 3 года**

**Автор-составитель:**

Магфурова Рамзия Нурулловна,
педагог дополнительного образования

## Белем бирү программасының мәгълүмати картасы

| | |
|---|---|
| 1. Белем бирү оешмасы | Мамадыш муниципаль районы Өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе “Балалар һәм яшүсмерләр йорты” |
| 2. Программаның тулы исеме | “Әдәби туган як”<br>өстәмә гомумбелем гомүмүсеш программасы |
| 3. Программаның юнәлеше | туристик-өлкәне һәм күренекле якташларыбызны өйрәнү |
| 4. Эшләүчеләр турында мәгълүмат: | |
| 4.1.Ф.И.О., вазифасы | Мәгьфурова Рәмзия Нурулла кызы, югары категорияле өстәмә белем бирү педагогы; |
| 5.Программа турында мәгълүмат: | |
| 5.1. Реализацияләү срогы | 3 ел |
| 5.2. Укучыларның яше | 11-17 яшь |
| 5.3 Программаның характеристикасы:<br>-программының тибы<br>-программың төре<br>-программаны проектлаштыру принцибы<br>-уку процессын һәм эчтәлекне оештыру формасы | өстәмә гомумбелем гомүмүсеш программасы |
| 5.4. Программаның максаты | Балаларда туган як, башка халыкларның тарихын, мәдәниятын, күренекле шәхесләребезнең хезмәтләрен өйрәнү аша толерантлык, көндәшлеккә сәләтлелек, патриотлык хисләре булдыру. |
| 6. Белем бирү эшчәнлегенең формалары һәм методлары | Теоретик һәм практик уку дәресләре, КТД, индивидуаль һәм коллектив проект эшчәнлеге, төрле дәрәҗәдәге конкурсларда һәм олимпиадаларда катнашу. |
| 7. Нәтиҗәлелек мониторингы формалары | Укучының диагностик картасы , портфолио , олимпиада һәм конкурслар, фәнни тикшеренү конференцияләре. |
| 8. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге | Контингент сакланышы: 100% |
| 9. Программаны раслау һәм соңгы төзәтмәләр кертү датасы | 28.08.2023 г.<br>31.05.2026 г. |
| 10. Рецензент | Р.Ф.Фәттахова, Тататарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы |

| | |
|---|---|
| | доценты, филология фәннәре кандидаты. |

**Эчтәлек**

1. Аңлатма язуы………………………………..……......…...……..........4

1.1.Актуальлек, педагогик максатчанлык, программаның яңалыгы…………………………………........…..............……...………..4

1.2. Аның башка белем бирү программаларыннан үзенчәлекле ягы ………………..……………..............................................................……...5

1.3. Программа адресланган балаларның яшь үзенчәлекләре……………………………………………....... …....………...5

1.4. Программаның максат һәм бурычлары……..………………....……….5

1.5. Программаны чынбарлыкка ашыруда катнашучы балаларның яшьләре…...…......................................................................................………6

1.6. Программаны тормышка ашыруның срогы һәм этаплары………………….........................................................…….......………6

1.7. Шөгыльләрнең формалары һәм режимы ……………………….........…6

1.8. Көтелгән нәтиҗәләр ……………………….................………….........7

1.9. Программаны тормышка ашыруда нәтиҗә чыгару формалары….......................................................................……………..............7

2. Уку планы

2.1. Беренче уку елына уку планы................……..……………........……....8

2.2 Икенче уку елына уку планы...............................................................12

2.3 Өченче уку елына уку планы...............................................................14

3. Программаны тормышка ашыруда методик, дидактик һәм материаль-техник тәэмин ителеш............................ ……………………........…………18

3.1. Өстәмә белем алучыларны укыту технологиясе, тәрбия һәм үсеш принциплары, формалары ……………………………...……......………19

3.2. Педагогик контроль……………………………….............…….......20

3.3. Дидактик материаллар…………………………………...........…...21

3.4. Материаль-техник тәэмин ителеш….. ………………...……......……..21

4. Әдәбият исемлеге……………………………………………......……..22

4.1. Педагог тарафыннан кулланылган әдәбият исемлеге.…....…......…....23

4.2 Ата-аналарга һәм балаларга тәкъдим ителгән әдәбият...........……....23

Искәрмә

## 1. Аңлатма язуы

Туган як...Туган туфрак... Туган төбәк... Бу сүзләр өлкән яшьтәге кешеләр өчен генә түгел, һәр сабый бала өчен дә газиз һәм кадерле булырга тиеш. Туган якның табигате, аңа бәйле кызыклы фактлар, аның тарихы, халыкның көнкүреше, гореф-гадәтләре, милли йолалары балаларга белем һәм тәрбия бирүдә зур роль уйный.

Милли төбәк компоненты халык һәм милләт үзенчәлеген, мәдәниятен һәм рухи дөньясын, телен һәм тарихын, табигый-географик мохитен, традицияләрен чагылдырган укыту материалын берләштерә.Укучы үзе яши торган төбәкнең табигатен , аның үзенчәлекләрен, халкын, традицияләрен, мәдәниятен, тарихын яхшы белергә тиеш.

Һәр төбәкнең үзенең күренекле шәхесләре була. Алар турында горурланып сөйләнелә, кылган гамәлләре хөрмәтләнә, яшь буынны да шулар үрнәгендә тәрбияләү максаты куела. Укучыларны туган якта туып үскән танылгын шәхесләр, төбәк фольклоры белән таныштырмый торып, әдәбияттан алар үзләштерергә тиешле белемне тулысынча алалар дип әйтеп булмый.

*Ватан –кешеләрнең хөрмәте һәм һәркем хозурында тора торган кадерле бер мактанычыдыр...Шуның өчен малыгызны кызганмагыз, көчләрегезне аямагыз, Ватан хакына болай фидакяр булмаган кеше анда яшәргә лаек түгелдер.*

*Риза Фәхретдин*

### 1.1.Программаның актуальлеге

Укучыларда туган як тарихы, мәдәнияте, әдәбият - сәнгате буенча белемнәр формалаштыру кирәклеге һәм куелган максат, бурычлардан чыгып билгеләнә.

Программаны тормышка ашырганда, сәламәтлекне саклау аспектлары да исәпкә алына: балаларның бина буенча күчеше чикләнми, физкультминуткалар үткәрелә; санитар-гигиеник норма һәм кагыйдәләр саклана. «Яшь тикшерүче» . программасы туган якны өйрәнү юнәлеше буенча түбәндәге документларга нигезләнеп эшли:

-  Россия Федерациясендә Мәгариф турында” Россия Федерациясенең федераль Законы (29.12.2012 №273-ФЗ);
- “Башлангыч урта федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау һәм кулланылышка кертү турында” приказы (6.10.2009 №373)
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм Фән министрлыгы Департаментының Хаты “Башлангыч урта федераль дәүләт белем бирү стандартын тормышка ашырганда, сыйныфтан тыш эшчәнлекне оештыру” ( 12.05.2011 №03)

- РТ Мәгариф Министрлыгының “Белем бирү учрежденияләрендә идарәче хезмәткәрләр, административ-хуҗалык, укыту-ярдәмче һәм хезмәт күрсәтүче персоналны раслаучы штат нормативлары” Боерыгы (24.04.1995 №135);
- Россия Мәгариф министрлыгының белем бирү учрежденияләрендә балаларга өстәмә белем бирү үсеше буенча методик рекомендацияләр ( 11.06.2002 №30-15-433/16);
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм Фән министрлыгының “Дәрестән тыш эшчәнлек һәм өстәмә белем бирү программалар” турындагы Хаты (14.12.2015);
- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең балаларга өстәмә белем бирү үсеше Концепциясен раслаучы Карары (4.09.2014 №1726);
- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясендә2025 нче елга кадәр чорда тәрбия үсеше Стратегиясе” Карары ( 29.05.2015);
- Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының “Татарстан Республикасында 2015-2025нче елларга балаларны тәрбияләү үсешенең Стратегиясе” Карары (17.06.2015 №443);
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм Фән министрлыгының “Информацияне юнәлдерү” турындагы Хаты ( Проектлы өстәмә гомуми үсеш программаларына методик рекомендацияләр белән) 18.11.2015 № 09-3242.

**1.2. Аның башка белем бирү программаларыннан үзенчәлекле ягы**

Әлеге программаның башка программалардан аермалы ягы шунда: ул гомуми һәм өстәмә белем бирү барышында әдәби, мәдәни, патриотик белем формалашуына, талантлы балаларны күрә һәм үстерә белүгә, хезмәт тәрбиясе һәм үзбилгеләнүне тәэмин итүгә корылган. Программа гамәли юнәлешле мөнәсәбәткә ия.

**1.3. Программа адресланган балаларның яшь үзенчәлекләре**

11-16 яшьлек балаларның төп үзенчәлеге булып, мөстәкыйль, иҗади (дивергент) фикерләү тора.

Яшүсмердә үзенең иҗади потенциалын, активлыгын тормышка ашырганда, кешелек системасы кыйммәтләре билгеләнә, яшьүсмернең үзенә һәм үзбәянең гаделлеге белән характерланучы уңай “Мин - концепция» формалаша.

**1.4. Программаның максат һәм бурычлары**

“Әдәби туган як” түгәрәге түбәндәге максаттан чыгып оештырыла: балаларда туган як, башка халыкларның тарихын, мәдәниятен өйрәтү аша толерантлык һәм патриотлык хисләре булдыру.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

-укучыларга үзләренең нәсел тамырларына, үз гаиләләренең үткәненә кызыксыну уяту;
-туган як тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә бәйле шәхесләрне, мәгариф һәм сәнгать тарихын эзлекле өйрәнү;
-укучыларда милли үзаң формалаштыру;
-тарихи шәһәрләргә, табигатькә экскурсияләр үткәрү.

## 1.5. Программаны чынбарлыкка ашыруда катнашучы балаларның яшьләре

"Әдәби туган як" курсы 11 -17 яшьлек балаларга исәпләнә.

## 1.6. Программаны тормышка ашыруның срогы һәм этаплары

Өстәмә белем бирү буенча бу программа 5 - 10 нчы класс укучылары өчен атнага 2 тапкыр 128 сәгатькә, бер уку елына төзелгән.Ул түбәндәге бүлекләрдән тора:
"Мин һәм минем гаиләм"
"Туган ягым "
" Районыбыз данын дөньяга таныткан якташларым"
"Татарстан – минем Республикам"

Һәр теманы өйрәнгәннән соң интеллектуаль уен, иҗади эш яки экскурсия планлаштырыла.

## 1.7. Шөгыльләрнең формалары һәм режимы

Берләшмәдә шөгыльләр түбәндәге формаларда үтә:

- традицион шөгыль;
- практик(гамәли) шөгыль;
- конкурслар;
- консультатив эшләр, проектны эшләү һәм яклау;
- күргәзмә;
- экскурсия;
- акция;
- викторина;
- кызыклы кешеләр белән очрашулар;
- түгәрәк өстәл;
- консультация;
- презентация;
- фәнни-практическ конференция.

Укыту процессын оештыруның төп формасы булып, гамәли шөгыльләр тора.

## 1.8. Көтелгән нәтиҗәләр

“Әдәби туган як” түгәрәгендә шөгыльләнгән бала:
-үз гаиләсе тарихына хөрмәт белән карый, горурлану хисләре кичерә;
-мөстәкыйль рәвештә ачышлар ясый,
-материал җыя, гомумиләштерә, мәктәп музеен тулыландыра;
-эзләнү эше алып бара, материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый;
- уеннар вакытында өйрәнгән материалны ныгыта;
-туган як әдәбияты, тарихы буенча белемнәрен арттыра;
-фәнни-тикшеренү эшләренә өйрәнә;
- үз – үзендә патриотизм, туган якка мәхәббәт хисе тәрбияли;
- туган төбәгенең тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә бәйле күренекле шәхесләре белән горурлана.

## 1.9. Программаны тормышка ашыруда нәтиҗә чыгару формалары

Түгәрәктә туган як әдәбияты һәм тарихы белән кызыксынган балалар шөгыльләнә.

Программа үзенең эчтәлеге белән төбәк тарихын үткәннән алып бүгенгесенә кадәр үз эченә ала.Туган як тарихын өйрәнү юллары һәм методлары төрле: семинар, экскурсия, очрашулар, төрле уеннар, эзләнү–тикшеренү эшләре һ.б. Аларны үткәрү укучының яшеннән, әзерлек дәрәҗәсеннән, түгәрәк занятиеләренең максатыннан тора. Бигрәк тә экскурсияләр укучыларда зур кызыксыну уята. Укучыларның түгәрәк белән кызыксынулары артсын өчен, укытучы үткәрү формаларын чиратлаштырып барырга тиеш.Балалар мөстәкыйль рәвештә документаль чыганакларны өйрәнеп, тикшеренү эшләре алып барырга омтылалар. Тикшеренү эшләре укытучы җитәкчелегендә алып барыла. Эшне оештырган укытучы үзе дә, беренчедән, төбәк тарихы буенча төп чыганакларны белергә тиеш. Икенчедән, үзе дә тикшеренү эше белән шөгыльләнергә, укучының эше белән кызыксынырга, өченчедән, туган як әдәбиятын, тарихын өйрәнү буенча класстан тыш эшләрдә оештыручы булырга тиеш.

Укучыларны бигрәк тә үзләренең күңелләренә якын булган, танышлары, якыннары катнашкан вакыйгалар, авылның барлыкка килүе кызыксындыра. Шуңа да тарих, әдәбият дәресләрендә тарихи вакыйга турында сөйләгәндә , бу вакыйганың безнең җирлеккә, авыл кешеләренә нинди мөнәсәбәте булуын аңлату кирәк.

Бу авторлык прогаммасы укучыларга туган төбәкнең тарихы , мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында тирәнрәк аңларга, төрле формадагы эзләнү эшләренә -гади язмадан башлап, фәнни-тикшеренү эшләренә кадәр - өйрәнергә мөмкинлек бирә .Программа буенча эшчәнлек нәтиҗәләре укучылар тарафыннан иҗади эшләр, реферат, фәнни-тикшеренү эшләре, презентацияләр һ.б. формасында тәкъдим ителә.

## 2.1. Беренче уку елына уку планы

| № п/п | Бүлек исемнәре | Сәгатьләр саны | | | Аттестация формалары/ контроль |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика | |
| 1 | Мин һәм минем гаиләм | 18 | 4 | 14 | Күзәтү, тестлаштыру, контроль сорау, контроль биремнәр , балаларның эшчәнлек ысулларын, аларның тикшеренү эшләрен анализлау, әңгәмә. |
| 2 | Туган ягым | 42 | 4 | 38 | |
| 3 | Районыбыз данын дөнья күгендә таныткан якташларым. | 40 | 6 | 34 | |
| 4 | Татарстан – минем республикам | 40 | 4 | 36 | |
| | Барлыгы: | 140 | 18 | 122 | |

***Программаның эчтәлеге***

**I бүлек. Мин һәм минем гаиләм**

Гаилә тарихын өйрәнү.Шәҗәрә турында аңлатма.Нәсел шәҗәрәләренең ерак тарихыбызны өйрәнү өчен мөһим чыганак булуы. Шәҗәрә төзү үрнәкләре.Нәселнең географиясе, нәсел башлыгын эзләп табу. Гаиләдә электән сакланган хатларны туплау, хатлардагы мәгълүматларны файдалану. Нәселнең шөгыльләрен, һөнәрләрен өйрәнү. Укымышлы һәм озын гомерле кешеләре турында мәгълүмат җыю. Гаилә традицияләре һәм аларны саклау. Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу. “Минем шәҗәрәм”. *“Шәҗәрәдә - гаиләм тарихы”- дәрес-конференция. Нәсел агачын төзү үрнәкләре.*

**II.Туган ягым.**

Шәһәргә нигез салыну. Исеме , риваятьләре, мәйданы, географик урыны, халкы, сулыклары, истәлекле урыннары, атамалары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән танышу. Авыл кешеләренең культурасы, гореф-гадәтләре. Бәет, җырлар чыгаручы кешеләр белән очрашу. Авыл һөнәрчеләре һәм һөнәрләре

турында мәгълүмат җыю, кул эшләреннән күргәзмә әзерләү, видеотасмага төшерү. Колхоз һәм башка оешмаларның тарихы. Хезмәт кешеләренең тормышын өйрәнү, төрле һөнәр ияләре белән очрашулар үткәрү. Бөек Җиңүнең 73 еллыгы уңаеннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш чоры балалары турында материаллар туплау, өйләрендә булу. Фәнни-тикшеренү эшләре башкару. Мәктәп, мәдрәсәләр тарихын өйрәнү, ветеран укытучылар, чыгарылыш укучылары белән очрашулар үткәрү, мәктәп тарихын язу күздә тотыла. Мәктәп музеена экскурсия. Төбәгебездәге күренекле кешеләрнең тормышларын өйрәнү, кылган гамәлләрен хөрмәтләү, яшь буынны шулар үрнәгендә тәрбияләү. *Истәлекле урыннарга сәяхәт.Чишмәләр,су буйларын күзәтү. Тарихи – экологик сукмак буйлап сәяхәт.*

**III. Районыбыз данын дөнья күгендә таныткан якташларым.**

Районыбыз данын дөнья күгендә таныткан якташларым турында мәгълүмат бирү. ”Мамадышым - язмышым” китабы белән танышу. Райондагы предприятиеләр турында әңгәмә. Районнан чыккан күренекле артистлар, язучылар, шагыйрьләр, аларның иҗаты белән танышу. Районныбызда булган музейларга экскурсия. *Әдәби – музыкаль кичә “Шушы яктан, шушы туфрактан без...”, Һөнәр сайлау кичәсе :*

*“Дәрәҗәле һөнәр иясе Сез , Без дә Сездән үрнәк алабыз”.*

**IV. Татарстан-минем Республикам**

ТР тарихы, географик урыны, символикасы, табигате, күренекле шәхесләре , шәһәрләре. Казан-чал тарихлы башкала. Алабуга-чор - дәверләр капкасы. Мамадышыбызга багышланган “Йолдызлы сәгать”уены үткәрү. Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсияләр. Күренекле шәхесләре турында әңгәмә . *Тамчы-шоу”уены.*

| № п/п | Темасы | Сәгать-ләр саны |
|---|---|---|
| 1 | “Әдәби туган як” түгәрәгендә техника куркынычсызлыгы һәм үз – үзеңне тоту кагыйдәләре.<br>Үз нәселеңне беләсеңме?-гаилә тарихын өйрәнү *(Әңгәмә, эзләнү)* | 2 |
| 2 | Хатлар ни сөйли? *(Эзләнү эше)* | 2 |
| 3 | Нәселем шәҗәрәсе | 2 |
| 4 | Нәселемнең укымышлы кешеләре. Нәселемнең озын гомерле кешеләре. *(Эзләнү эше)* | 2 |
| 5 | Нәселем традицияләре *(Язма эш)* | 2 |
| 6 | Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу | 2 |
| 7 | “Шәҗәрәдә гаиләм тарихы” | 2 |
| 8 | *Нәсел агачын төзү үрнәкләре* | 2 |
| 9 | *Нәсел агачын төзү* | 2 |
| 10 | Шәһәребез тарихы | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 11 | Шәһәребез исеме каян килеп чыккан? *(Эзләнү эше)* | 2 |
| 12 | Шәһәребездәге  географик атамалар һәм аларның тарихы *(Өлкән кешеләр белән очрашып язып алу)* | 2 |
| 13 | Шәһәребездәге  һөнәрләр һәм һөнәрчеләр . Мәктәп музеена экскурсия | 2 |
| 14 | Щербаковлар җитәкләгән спирт завод тарихы. | 2 |
| 15 | Щербаковлар  һәм эшчеләр арасында мөнәсәбәт.  Җирлегебез үсешенә аларның йогынтысы. | 2 |
| 16 | Сугыш чоры балалары *(Эзләнү эше,очрашулар)* | 2 |
| 17 | Мәктәп тарихы *(Мәктәп музеендагы бүлекләр  белән танышу)* | 2 |
| 18 | Мәктәпнең элекке укытучылары *( Мәктәп музеендагы экспозиция белән танышу, өстәмә материаллар туплау)* | 2 |
| 19 | Ветеран укытучыларның өйләрендә булу (*очрашу*) | 2 |
| 20 | Шәһәребезнең  тарихи урыннары.  Пузанка тавы, чишмәләр, су буйларын күзәтү.*Экскурсия.* | 2 |
| 21 | Эзләнү – тикшерenү эшләре | 2 |
| 22 | Эзләнү – тикшерenү эшләре | 2 |
| 23 | Эзләнү – тикшерenү эшләре | 2 |
| 24 | Эзләнү – тикшерenү эшләре | 2 |
| 25 | Эзләнү – тикшерenү эшләре | 2 |
| 26 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 27 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 28 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 29 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 30 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 31 | Мамадыш районы тарихы *битләреннән. “Мамадышым -язмышым”.* | 2 |
| 32 | Мамадыш районы тарихы *битләреннән. “Мамадышым -язмышым”.* | 2 |
| 33 | Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый ! *Районыбыздагы һәйкәлләр турында.* | 2 |
| 34 | Райондагы промышленность предприятиеләре | 2 |
| 35 | Райондагы промышленность предприятиеләре | 2 |
| 36 | Районыбызның авыл хуҗалыгы | 2 |
| 37 | Районыбызның авыл хуҗалыгы | 2 |
| 38 | Мамадышның сәхнә йолдызлары – күренекле артистлар | 2 |
| 39 | Мамадышның сәхнә йолдызлары – күренекле артистлар | 2 |
| 40 | Тукай премиясе иясе булган якташларыбыз. | 2 |
| 41 | Шәйхи Маннур, Ш.Мостафин  иҗаты белән танышу. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 42 | Туган ягыбызда яшәп иҗат итүче шагыйрьләребез һәм язучыларыбыз | 2 |
| 43 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 44 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 45 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 4 |
| 46 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 47 | Район конкурс-бәйгеләрен-дә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 48 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 49 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 50 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 51 | ТР тарихы | 2 |
| 52 | Татарстанның символикасы | 2 |
| 53 | ТР географик урыны | 2 |
| 54 | Татарстанның табигате | 2 |
| 55 | ТР шәһәрләре<br>Республика шәһәрләре белән таныштыру.Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсия ясау. | 2 |
| 56 | Казан-чал тарихлы башкала. | 2 |
| 57 | Алабуга - чор -дәверләр капкасы. | 2 |
| 58 | Күренекле шәхесләр | 2 |
| 59 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 60 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 61 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 62 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 63 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 64 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 65 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 66 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 67 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 68 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 69 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 |
| 70 | Йомгаклау | 2 |

## 2.2. Икенче уку елына уку планы

| № п/п | Бүлек исемнәре | Сәгатьләр саны | | | Аттестация формалары/ контроль |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика | |
| 1 | Район тарихы, этногафиясе | 26 | 8 | 18 | Күзәтү, тестлаштыру, контроль сорау, контроль биремнәр , балаларның эшчәнлек ысулларын, аларның тикшеренү эшләрен анализлау, әңгәмә. |
| 2 | Туган ягым | 42 | 4 | 38 | |
| 3 | Районымның күренекле кешеләре | 60 | 50 | 10 | |
| | Барлыгы: | 128 | 62 | 66 | |

***Программаның эчтәлеге***

**I . Мин һәм минем гаиләм**

Гаилә тарихын өйрәнү. Шәҗәрә турында аңлатма.Нәсел шәҗәрәләренең ерак тарихыбызны өйрәнү өчен мөһим чыганак булуы. Шәҗәрә төзү үрнәкләре.Нәселнең географиясе, нәсел башлыгын эзләп табу. Гаиләдә электән сакланган хатларны туплау, хатлардагы мәгълүматларны файдалану. Нәселнең шөгыльләрен, һөнәрләрен өйрәнү. Укымышлы һәм озын гомерле кешеләре турында мәгълүмат җыю. Гаилә традицияләре һәм аларны саклау. Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу. “Минем шәҗәрәм”. *Нәсел агачын төзү үрнәкләре.*

**II.Туган ягым.**

Туган ягыбызның тарихи урыннары, атамалары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән танышуны дәвам итү.Кешеләренең культурасы, гореф-гадәтләре. Бәет, җырлар чыгаручы кешеләр белән очрашу. Авыл һөнәрчеләре һәм һөнәрләре турында мәгълүмат җыю, кул эшләреннән күргәзмә әзерләү, видеотасмага төшерү. Хезмәт кешеләренең тормышын өйрәнү, төрле һөнәр ияләре белән очрашулар үткәрү. “Җиңү көне” уңаеннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш чоры балалары турында материаллар туплау, өйләрендә булу. Фәнни-тикшеренү эшләре башкару. Мәктәп , мәдрәсәләр тарихын өйрәнү,

ветеран укытучылар , чыгарылыш укучылары белән очрашулар үткәрү, мәктәп тарихын язу күздә тотыла. Мәктәп музеена экскурсия. Төбәгебездәге күренекле

кешеләрнең тормышларын өйрәнү, кылган гамәлләрен хөрмәтләү, яшь буынны шулар үрнәгендә тәрбияләү.

**III. Районымның күренекле кешеләре.**

Районымның күренекле кешеләре турында мәгълүмат бирү. ”Мамадышым - язмышым” китабы белән танышу. Райондагы предприятиеләр турында әңгәмә. Районнан чыккан күренекле артистлар, язучылар, шагыйрьләр, аларның иҗаты белән танышу.

| № | Темалар | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | Мамадышым – туган ягым. | 2 |
| 2 | Районыбыз тарихы. | 2 |
| 3 | Мамадыш төбәгенең гореф-гадәтләре һәм әби-бабаларыбызның йолалары. | 2 |
| 4 | Туган ягыбызда тел үзенчәлекләре-диалектлар | 2 |
| 5 | Тарихи корылмалар. | 2 |
| 6 | Тарихи корылмалар тарихы белән бәйле шәхесләр. | 2 |
| 7 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 8 | Районыбыздан чыккан күренекле кешеләр (һөнәр ияләре, хезмәт алдынгылары). | 2 |
| 9 | Данлыклы шәхесләребез.<br>Районнан чыккан язучылар һәм сәнгать әһелләре белән таныштыру. | 2 |
| 10 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 11 | Шәһәребезгә шәһәр статусы бирелү. | 2 |
| 12 | Районыбызның алдынгы колхозлары һәм совхозлары. | 2 |
| 13 | Авылларда оештырылган яшелчә һәм алма бакчалары. | 2 |
| 14 | “Тыйнак хезмәт кешеләре...” – тырыш терлекчеләр турында сөйләшү. Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 15 | Кешеләренең культурасы һәм көнкүреше | 2 |
| 16 | Районда мәгариф тарихы.Мәдрәсәләр. Мәгариф шәҗәрәсе. | 2 |
| 17 | Беренче мәктәпләр. Яңа мәктәп төзелү. | 2 |
| 18 | Бөек Ватан сугышында катнашкан укытучылар. Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 19 | Якташларыбыз Бөек Ватан сугышында. | 2 |
| 20 | “Баш иябез Сезгә! “Бөек Җиңү” – Бөек Ватан сугышы темасына район, республика кокнурсларында катнашу. | 4 |
| 21 | “Һәйкәл куяр идем мин коеп” – тыл хезмәтчәннәренең Бөек | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | жиңүгә керткән өлеше. | |
| 22 | “Берлинны алган егетләр ” – Берлинга барып җиткән якташлар турында материал туплау | 2 |
| 23 | “Баш иябез Сезгә!” – сугыш һәм тыл ветераннары белән очрашу. | 2 |
| 24 | Кемнәр алар интернационалистлар? Алар Ватан алдындагы бурычларын үтәделәр | 2 |
| 25 | “Акланган исемнәр...” Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 26 | “Тарихларда җуелмас сукмагы бар”. Нәҗип Нәккашның иҗади эшчәнлеге. | 2 |
| 27 | Затлы нәсел элек һәм хәзер. Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 28 | “Элек шәмгә мохтаж яклар...”- Районга электр кетү тарихы. | 2 |
| 29 | “Хезмәте барның – хөрмәте бар” алдынгы эшчеләр турында материал туплау. | 2 |
| 30 | Хезмәте барның – хөрмәте бар” материал туплау. | 4 |
| 31 | Хезмәт белән данланган якташларым. Социалистик Хезмәт Геройлары белән танышу. | 2 |
| 32 | Промышленность үсеше. | 2 |
| 33 | Мәгариф тарихы. Мәдрәсәләр. Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 34 | РСФСР ның атказанган укытучылары. | 2 |
| 35 | Мәктәбебез тарихы. “Алар бездә укыдылар” эзләнү-тикшеренү эше. | 2 |
| 36 | Сәнгать үсешенә күзәтү. | 2 |
| 37 | Мәдәният йортына сәяхәт оештыру. | 2 |
| 38 | Фән өлкәсендә зур казаныш яулаган якташларыбыз. | 2 |
| 39 | Зур уңышларга ирешкән хәрбиләребез. | 2 |
| 40 | Якташ академикларыбыз һәм професссорларыбыз.. | 2 |
| 41 | Сәнгать өлкәсендә танылу алган якташларыбыз. | 2 |
| 42 | “Өлге булырлык якташым” эзләнү- тикшеренү эше. | 2 |
| 43 | Район, республика конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау. | 2 |
| 44 | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 34 |
| 45 | Йомгаклау | 2 |
| | | 128 |

## 2.3. Өченче уку елына уку планы

| № п/п | Бүлек исемнәре | Сәгатьләр саны | | | Аттестация формалары/ контроль |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика | |
| 1 | **Мамадышым – язмышым** | 16 | 4 | 12 | Күзәтү, |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | **Милли төбәк** | 28 | 6 | 24 | тестлаштыру, контроль сорау, контроль биремнәр , балаларның эшчәнлек ысулларын, аларның тикшеренү эшләрен анализлау, әңгәмә. |
| 3 | **Ватаным дип тибә йөрәк** | 22 | 8 | 14 | |
| 4 | **Мамадыш: риваятьләр һәм мифлар** | 20 | 4 | 16 | |
| 5 | **Китапта – татар халык авыз иҗаты** | 30 | 18 | 12 | |
| | Барлыгы: | 128 | 40 | 78 | |

***Программаның эчтәлеге***

**I . Мамадышым –язмышым**

Тарихи-мәдәни, археологик истәлекләр. Нократ елгасы турында истәлекләрне барлау. Кирмән төбәгендәге серләр сандыгын ачу.

Бөрсет бакыр заводы тарихын барлау, мәгълүмат туплау. Мамадыш төбәгендә Е.Пугачев яуларының булган урыннарын ачыклау.

Бөрсет бакыр заводы хакында мәгълүмат.

*Бөрсет бакыр заводы хакында мәгълүмат белән таныштырыр өчен Югары Кыерлы авылының тарихын язган, бу хактагы 3 китап авторы Рәис Шаһи, биолгия, химия укытучысы Мухаметзянов Захыт Сафиуллаевич белән очрашу.*

**II. Милли төбәк.**

Төбәгебез кешеләренең культурасы, гореф-гадәтләре. Бәет, җырлар чыгаручы кешеләр белән очрашу. Шәһәр һөнәрчеләре һәм һөнәрләре турында мәгълүмат җыю, кул эшләреннән күргәзмә әзерләү, видеотасмага төшерү. Оешмаларның тарихы. Хезмәт кешеләренең тормышын өйрәнү, төрле һөнәр ияләре белән очрашулар үткәрү. Фәнни-тикшеренү эшләре башкару. Киләчәккә зур өметләр баглап (шәһәр төзелеше турында әңгәмә).

Мәктәп, мәдрәсәләр тарихын өйрәнү, ветеран укытучылар , чыгарылыш укучылары белән очрашулар үткәрү, мәктәп тарихын язу күздә тотыла. Мәктәп музеена экскурсия. Төбәгебездәге күренекле кешеләрнең тормышларын өйрәнү, кылган гамәлләрен хөрмәтләү, яшь буынны шулар үрнәгендә тәрбияләү. *Җирле язучылар, шагыйрьләрне өйрәнү. Сәяф Шәйхи иҗатына багышланган кичә үткәрү.Истәлекле урыннарга сәяхәт.Чишмәләр,су буйларын күзәтү. Тарихи – экологик сукмак буйлап сәяхәт.*

**III. Ватаным дип тибә йөрәк**

Бөек Ватан сугышында катнашкан якташларыбыз турында мәгълүмат бирү, туплау. Әфганчылар белән танышу. Мамадыш сәнгать мәктәбе тарихын өйрәнү. Мамадышка багышланган җырларны барлау. Мамадышның тарихи һәм истәлекле урыннарын өйрәнү. Беренче татар китабы. Типография ачылу тарихы.Татар китабын басучы нәшриятлар, Татарстан китап нәшрияты турында мәгълүмат туплау.

*Туган ягым буйлап сәяхәт (түгәрәк өстәл). Китап – белем чишмәсе. Китаплар иленә сәяхәт. Районның Туган як музеена, чишмәләргә экскурсия. Әдәби – музыкаль кичә "Шушы яктан, шушы туфрактан без...", Һөнәр сайлау кичәсе : "Дәрәҗәле һөнәр иясе Сез , Без дә Сездән үрнәк алабыз".*

**IV. Татарстан-минем Республикам**

ТР тарихы, географик урыны, символикасы, табигате, күренекле шәхесләре , шәһәрләре. Казан-чал тарихлы башкала. Алабуга-чор - дәверләр капкасы. Казан шәһәренә багышланган "Йолдызлы сәгать"уены үткәрү. Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсияләр. Күренекле шәхесләре турында әңгәмә . *Тамчы-шоу"уены.*

**V. Китапта – татар халык авыз иҗаты**

Татар халык авыз иҗаты жанрларын искә төшерү. Халык авыз иҗаты әсәрләре тупланмасы. "Балалар фольклоры" китабы. Н.Исәнбәт һәм Р.Ягъфәров төзегән китаплар белән танышу.Табышмаклар әйтешү.Әкият язу. Бишек җырларын өйрәнү. Татар халык уеннары.Китапларда – җырлар, бәетләр, дастаннар. Алар тупланган китаплар белән танышу.

*Шәһәребез мәчетенә, китапханәсенә экскурсия.ТР Милли китапханәсенә экскурсия (читтән торып яки үзенә барып). Татар китабы – сәхнәдә, театрга сәяхәт (читтән торып яки үзенә барып). Түгәрәкне йомгаклау.*

| | | |
|---|---|---|
| | **I. Мамадышым –язмышым** | |
| 1. | Район исеме ни сөйли? Тау башында – Ак кала, Мамадыш дип атала. | 2 |
| 2. | Мамадыш районы географиясе. | 2 |
| 3. | Тарихи-мәдәни, археологик истәлекләр. | 2 |
| 4. | Ачыла тарих битләре. Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 5. | Безнең илләр – Нократ. | 2 |
| 6. | Кирмән төбәге – серләр сандыгы. | 2 |
| 7. | Бөрсет бакыр заводы. | 2 |
| 8. | Ул елларның кайтавазы. Мамадыш төбәгендә Е.Пугачев яулары. | 2 |
| | **II. Милли төбәк** | |
| 9. | Без ничек сөйләшәбез? | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Милли традицияләр, гореф-гадәтләр.<br>“Мамадышымны милли итеп күрәсем килә”. (Түгәрәк өстәл) | 2 |
| 11. | Әби-бабай сүзе – күңел күзе.<br>Фольклор үрнәкләре: табышмаклар, мәкальләр, әйтемнәр, сынамышлар. | 2 |
| 12. | Район мәгарифе тарихы, мәгарифнең үткәненә телдән экскурсия | 2 |
| 13. | Кемнән үрнәк алырга? (Укытучылар династиясе) | 2 |
| 14. | Мин укыган мәктәп. Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 15. | Мамадышта халыклар дуслыгы | 2 |
| 16. | Фән һәм тел, тәрбия үсешенә өлеш керткән галимнәр һәм олы шәхесләр. | 2 |
| 17. | Сәнгатькә гашыйк кешеләр. | 2 |
| 18. | Якташларыбыз-горурлыгыбыз”. Спорт һәм без “сөйләшүе. | 2 |
| 19. | Җирнең чын хуҗалары. Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 20. | Районыбыз шагыйрьләре. | 2 |
| 21. | Җирле язучылар, шагыйрьләр. | 2 |
| 22. | Киләчәккә зур өметләр баглап (шәһәр төзелеше турында әңгәмә) | 2 |
| | **III. Ватаным дип тибә йөрәк** | |
| 23 | Бөек Ватан сугышы геройлары – якташларыбыз. | 2 |
| 24 | Җәлил көрәштәшләре | 2 |
| 25 | Әфганчылар | 2 |
| 26 | Мамадыш сәнгать мәктәбе. | 2 |
| 27 | Рәсемнәр һәм сурәтләр дөньясында.. | 2 |
| 28 | Мамадышка багышланган җырларны барлау. Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 |
| 29 | Мамадышның тарихи һәм истәлекле урыннары | 2 |
| 30 | Туган ягым буйлап сәяхәт (түгәрәк өстәл) | 2 |
| 31 | Китап – белем чишмәсе. Китаплар иленә сәяхәт. | 2 |
| 32 | Беренче татар китабы. Типография ачылу тарихы. | 2 |
| 33 | Татар китабын басучы нәшриятлар, Татарстан китап нәшрияты турында. | 2 |

**IV. Татарстан-минем Республикам**

ТР тарихы, географик урыны, символикасы, табигате, күренекле шәхесләре , шәһәрләре. Казан-чал тарихлы башкала. Алабуга-чор - дәверләр капкасы. Казан шәһәренә багышланган “Йолдызлы сәгать”уены үткәрү. Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсияләр. Күренекле шәхесләре турында әңгәмә . *Тамчы-шоу”уены.*

| | | |
|---|---|---|
| | **IV. Мамадыш: риваятьләр һәм мифлар** | |
| 34. | ТР тарихы, географик урыны, символикасы, табигате, күренекле шәхесләре , шәһәрләре. | 2 |
| 35. | Казан-чал тарихлы башкала. | 2 |
| 37. | Казан шәһәре буйлап вертуаль экскурсия. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 38. | Башкаланың тарихи урамнары. | 2 |
| 39. | Казанда мәдәни ял итү урыннары | 2 |
| 40. | Башкалабыздагы югары уку йортлары. | 2 |
| 41. | Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсияләр. | 2 |
| 42. | Алабуга-чор - дәверләр капкасы. | 2 |
| 43. | Күренекле шәхесләре турында әңгәмә . | 2 |
| 44. | *Тамчы-шоу”уены.* | 2 |
| V. **Китапта – татар халык авыз иҗаты** | | |
| 45. | Табышмак – бил алышмак. | 2 |
| 46. | Отканга – мәкаль, тапкырга – табышмак. | 2 |
| 47. | Әкиятләр. | 2 |
| 48. | Бишек җырлары – тәрбиянең бик борынгы чарасы. | 2 |
| 49. | Китапта – уеннар. | 2 |
| 50. | “Балалар фольклоры” китабы. Н.Исәнбәт һәм Р.Ягъфәров төзегән китаплар. | 2 |
| 51. | Китапларда – җырлар, бәетләр, дастаннар. | 2 |
| 52. | Халык авыз иҗаты әсәрләре тупланмасы. | 2 |
| 53. | Шәһәр мәчетенә, китапханәсенә экскурсия | 2 |
| 54. | Тәрбия китаплары | 2 |
| 55 | ТР Милли китапханәсенә экскурсия (читтән торып яки үзенә барып) | 2 |
| 56. | Татар халык язучыларының томнары | 2 |
| 57. | Татар халык шагыйрьләренең китаплары | 2 |
| 58. | Бөек шагыйребез Г.Тукайның төрле елларда басылган томнары | 2 |
| 59. | Татар китабы – сәхнәдә, театрга сәяхәт (читтән торып яки үзенә барып). Түгәрәкне йомгаклау. | 2 |

### *3.1 Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре*

Бу программаны үзләштерүнең төп белем нәтиҗәсе булып туган як тарихына, үткәненә, киләчәгенә карата җаваплы караш, баланың патриотик аңын үстерү, туган ягы, тарихы хакында хәбәрдар, актив өйрәнү эшчәнлегенә әзерлек формалаштыру, тәрбияләнүчеләрнең иҗади потенциалын ачу тора.

Метапредмет нәтиҗәләре:

- Тикшеренү һәм проект эшчәнлеген үз эченә алган, шул исәптән проблеманы күрә, сораулар куя, күзәтә, экспериментлар үткәрә, нәтиҗәләр ясый һәм, материалны структуралаштыра, аңлату, үз идеяләрен раслый, яклый белүне дә кертеп.

Шәхси нәтиҗәләр

Укучыларда формалаша:

- танып-белү активлыгы һәм туган якны өйрәнү юнәлешле эшчәнлектә катнашу ихтыяҗы;

- гомуми этник культура;
- игелек, ярдәмчеллек һәм тирә-юньдәгеләргә игътибар);
- социаль һәм табигый мохит белән хезмәттәшлек итә белү;

Фән нәтиҗәләре

- Тарихи чыганаклар һәм этноска хас билгеләрне билгеләү;
- Кешенең һәм әйләнә-тирәлекнең үзара бәйләнеше һәм кеше яшәешенә әйләнә-тирәлекнең бәйле булуы; туган төбәкнең тарихын белү ихтыяҗы
- Кешеләрнең практик эшчәнлегендә туган якның ролен аңлату; кешенең әйләнә-тирәлектә урыны һәм роле. Программаны тормышка ашыруда методик, дидактик һәм материаль-техник тәэмин итү.

### *3.2. Өстәмә белем алучыларны укыту технологиясе, тәрбия һәм үсеш принциплары, формалары*

**Программа укытуның түбәндәге дидактик принципларына нигезләнә:**

- иреклелек принцибы, кешелеклелек, гомумкешелек кыйммәтләренең өстенлеге, шәхеснең ирекле үсеше, белем алучыларның шәхси һәм иҗади үсеше өчен максималь уңай атмосфера тудыру ( “уңыш ситуациясе», үстерелешле аралашу);
- мөмкинлек һәм эзлеклелек принцибы – уку процессын гадидән катлаулыга таба төзү, материалны тәкъдим итү һәм аңлауның гадилеге;
- табигый зиһенлелек принцибы: бер эш төреннән икенчесенә күчергәндә, балаларның яшь үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алу
- индивидуальлек принцибы: һәр тәрбияләнүченең максималь мөмкинлеген исәпкә алу;
- креативлылык принцибы: белем алучыларның иҗади сәләтләре үсеше;
- фәннилек принцибы: уку курсы заманча фәнни уңышларга нигезләнә;
- күрсәтмәлелек принцибы: укыту-тәрбия процессын нәтиҗәле итүче күрсәтмә һәм дидактик ярдәмлекләрне, укытуның техник чараларын киң куллануны күз алдында тота;
- теорияне практика белән бәйләү принцибы, укуның тормыш-көнкүреш белән элемтәсе, балалар белән эш барышында гамәли белем һәм күнекмәләрнең теоретик белемнәр белән гадәти туры килүе, алган белемнәрне практикада куллану мөмкинлеге; принцип системности и преемственности в обучении;
- белем бирүнең аңлылык һәм активлык принцибы;
- укытуның интеграль принцибы (төрле эшчәнлек төрләренә параллель һәм бер-берсен тулыландырып укыту);
- хезмәттәшлек принцибы: өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге;
- предметара бәйләнеш принцибы: башка фәннәр белән яки эшчәнлекнең башка төрләре белән бәйләнеш.

***Укыту методлары (белем алучыларның эшчәнлек характеры буенча):***

-  Информацион-рецептив;
-  Аңлатма-иллюстратив;
-  Репродуктив методлар;
-  Өлешчә эзләнүле;
-  Проблемалы;
-  Эзләнү-тикшеренү методлары.

***Нигезендә шөгыльләрне оештыру ысулы яткан белем бирү методлары ( материалны бирү ысулы буенча):***

-  Сүзле (материалны телдән хикәяләү, материалны проблемалы хикәяләү, хикәяләү, әңгәмә, аңлату, анализ һәм б.ш.);
-  Күрсәтмә (видео һәм аудиоматериалларны , иллюстрацияләрне күрсәтү, плакатларны демонстрацияләү);
-  Гамәли (иҗади, фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнү).

Шөгыльләрне үткәрү методикасы өйрәнә торган материалның катлаулылыгын, эзләнү эшләре башкарганда, кыенлыкларны җиңү шатлыгын; һәрвакыт уңышлылык ситуациясен күз алдында тота . Моңа биремнәрне, эзләнү эшләрен башкарганда бердәм фикер йөртү, шулай ук хуплау, уңай мотивация тудыру, кызыксынуны актуализацияләү, конкурслар, фәнни-гамәли конференцияләр булышлык итә.

Өйрәнгән материал кысаларында укучыларга эзләнү эшләрен, аларны үтәү формаларын( индивидуаль, группа, коллектив белән) сайлау хокукы бирелә.

***Түгәрәкнең шөгыльләре түбәндәге формаларда үтә:***

-  традицион шөгыльләр;
-  гамәли шөгыльләр ;
-  конкурслар;
-  консультация бирү характерындагы эшләр, проектны эшләү һәм яклау;
-  күргәзмә;
-  экскурсия;
-  акция;
-  викторина;
-  кызыклы кешеләр белән очрашулар;
-  түгәрәк өстәл;
-  күзәтү;
-  консультация;
-  презентация;
-  фәнни-гамәли конференция.

Укыту процессын оештыруның төп формасы булып гамәли шөгыльләр тора.

**Кулланыла торган заманча белем бирү технологияләре:**

-  Сәламәтлекне саклау, белем бирү  технологияләре (ЗОТ).
-  Критик фикер йөртү технологиясе (ТРКМ).
-  Проект эшчәнлеге.
-  Коллектив иҗади эшләр (КТД).
-  Проблемалы  укыту технологиясе.
-  «Дебаты» технологиясе .
-  Хезмәттәшлеккә өйрәтү.
-  Группалы технологияләр.
-  Акыл эшчәнлегенең этаплы формалашу технологиясе.
-  Коллектив тәэсир итү технологиясе..
-  Модульле укыту технологиясе.

### 3.3. Педагогик контроль

***Диагностик -*** педагог аның ярдәмендә  тәрбияләнүчеләдә психик процессларның үсеш дәрәҗәсен билгели ( хәтер, игътибарлылык, фикерләү,күзаллау һ.б.)   Педагог тарафыннан бәяләү контроле үткәрелсә дә, нәтиҗәсе белән укучыларны таныштырмый).  Аның ярдәмендә түбәндәгеләрне ачыклап була:

-  укучыларның танып белү мөмкинлеге һәм үзенчәлегенең дәрәҗәсе;
-  белемнәрне һәм эшчәнлек төрләрен үзләштерү тизлеге;
-  өлгерүчәнлек һәм түгелгән көчне чагыштыру;
-  белемгә, нинди дә булса эшчәнлеккә һәвәслек;
-  баланың туган якны өйрәнү берләшмәсенә килү мотивы;
-  баланың буш вакытларындагы шөгыле һ.б.

***Констатирующий (билгеләүче)  контроль*** ярдәмендә  укучының нинди дә булса биремне үтәү фактын билгеләп була. Нәтиҗә “әйе-юк” формасында бәяләнә.

***Тикшерүче  контроль*** – тәрбияләнүчеләрнең  белем һәм күнекмәне  ни дәрәҗәдә алуларын ачыклый.

### 3.4. Дидактик  материаллар

-  Демонстрацион  материал (фотографияләр, хатлар, видеороликлар, карталар һ.б.);
-  Таратма материал (билгеле уку бурычлары куелган дифференциаль яки индивидуаль характердагы  биремнәр)..

### 3.4. Материаль-техник  тәэмин ителеш

-  Компьютер, принтер, сканер.
-  Медиапроектор
-  Күргәзмә өчен стендлар.
-  Укыту-ярдәмче биналар:  татар теле һәм әдәбияты, тарих кабинеты, китапханә, туган якны өйрәнү музее.

## 4. *Әдәбият исемлеге*

### *4.1. Педагог тарафыннан кулланылган әдәбият исемлеге*

1. Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.-128б.
2. Баязитова Н. Урман җыры. Түбән Кама. 2009.-140б..
3. Батырлар китабы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000.- 395 б.
4. Галләмова Г. Матур булып үсегез . “Ихлас” нәшрияты. 2011 -46б.
5. Гарипова Ф.Г. Исемнәрдә ил тарихы. –Казан, 1994. – 263 б.
6. Вәлиев Р. Сайланма әсәрләр.– Казан: “Милли китап” нәшр.,2000.-672 б.
7. Солтанова Р. “Мул кояшлы булсын язларым”
8. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. - Казан, 1981. – 255 б.
9. Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. -256 б.
10. Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы.–Казан: КДУ нәшр., 1990.- 278б.
11. Саттаров Г. Ни өчен шулай аталган? ТКН, Казан, 1971.

*(рус телендә)*

1. Есть вечное слово Учитель/ сост. В.А. Иванова.- Нижнекамск: изд-во УМЦ, 2004. – 98 с.
2. Поэты света и тепла. – Казань: изд-во «Идел-Пресс», 2005.- 520 с.
3. Сафиуллина Ф.С. Татарский язык. Интенсивный курс. – Казань, 2001.
4. Я знаю, город будет!.., Казань,1996. - 45 с.

**Укучы өчен әдәбият** (татар телендә)

1. Баязитова Н. Урман җыры.Түбән Кама.2009-140б.
2. Булатова К. Хәтер көзгесе.Уфа,1995.-79б.
3. Вәлиев Р. Сайланма әсәрләр.– Казан: “Милли китап” нәшр., 2000.-672 б
4. Вәлиуллина И. Аккошлы күл. – Казан, 2006. – 160 б.
5. Галләмова Г. Матур булып үсегез. Түбән Кама. “Ихлас”.2009-46б.
6. Имаев Р. Алма балланган вакыт. – Казан, 2007. – 154 б.
7. Ибраһимов М. Фатих Кәрими. “Рухият”, 2000.-24б.
8. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. - Казан, 1981. – 255 б.
9. Фәхретдин Р. Шәкертлек әдәбе. Әлмәт, 2004.

10. Хәйдәрова Р.З., Малафеева Р.Л. Татар теле. 8-11 сыйныф. Рус телендә сөйләшүче балаларга дәреслек. - Казан: «Мәгариф» нәшр., 2007 ел.

*(рус телендә)*

1. Абдуллин Ф. Литература родного края.- Нижнекамск: изд-во УМЦ, 2006. – 200 с.

2. Сафиуллина Ф.С. Татарский язык. Интенсивный курс. Казань, 2001.

### *4.3 Ата-аналарга һәм балаларга тәкъдим ителгән әдәбият исемлеге*

1. Краеведение в школе. – Педагогическая энциклопедия, т.2.М., Советская энциклопедия,1965, с. 518-520.

2. Краеведческая программа. “Литературное краеведение”, составлена С.С.Кулаковой.

3. В.Е.Туманов. Школьный музей-хранитель народной памяти.М., 2006.

4. А.С.Тайсин. Татарстан Республикасы географиясе. Гомуми урта белем мәктәбенең 8-9 классларı өчен уку ярдәмлеге. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2002 ел. – 230 б.

5. Большая Советская Энциклопедия. – третье издание. – Москва: Издательство “Советская энциклопедия”, 1972. – стр. 606

6. Книга памяти о советских воинах, погибших в Афганистане.-т-2, Москва, Военное издательство, 1999

7. “Мәйдан “журналы

8.”Мәгариф”журналлары

9. Музей материаллары.

10. Протащук И.Ю.Гаилә елъязмалары.Казан -2009.

11.Татарстан тарихы.Төп мәктәп өчен уку әсбабы.-Казан.-ТаРИХ, 2001

12.Хәтер.Татарстан Республикасы, Казан, Хәтер китабы нәшр.,1996.

### *Өстәмә белем бирү программасының методик яктан тәэмин ителеше*

1. 2004 - 2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы //Мәгариф. – 2005. - №1. – Б. 38.

2. Татар мәктәпләрендә татар балаларына татар теле һәм әдәбияты укыту программалары. – Мәгариф, 2010.

3. “Мәгариф”журналлары

4. Краеведческая программа. “Литературное краеведение”, составлена С.С.Кулаковой.

5. Интернет- ресурслар: “Открытый класс”, “Белем ru.” Һ.б сайтлар.

6. Аудиокассеталар: “Җидегән йолдыз. Флера Гыйззәтуллина”; “Марсель Галиев шигырьләренә язылган җырлар”; “Татар халык әкиятләре” һ.б.

7. Аудио һәм DVD  дисклар: “Татар җырлары. 1500 караоке ”, “Классик әдәбиятыбыз үрнәкләре, “Шигърият бакчасында. Татар халык авыз иҗатыннан үрнәкләр” һ.б.